ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.02.2026 с.Старое Дрожжаное №5

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 01 декабрендәге 48 номерлы (14.02.2019 № 11, 25.07.2023 № 32, 13.10.2023 № 43, 28.05.2024 № 13 ред.) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2 бүлекнең 2.1 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Гражданның мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язмача яисә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып электрон документ формасында җибәрелә (алга таба - Бердәм портал), җирле үзидарә органының йә җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге гражданнарның идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин итә торган башка мәгълүмат системасы (әгәр дә 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса), тәкъдим, гариза яисә шикаять, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгате;»;

**7 бүлекнең 7.2 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.2. Гражданның язмача бирелгән мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать җибәрелгән органның исеме, яки тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, этисенең

исеме, яки тиешле затның вазыйфасы, шулай ук тәкъдимнең, гаризаның яки шикаятьнең асылы, гражданның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы - булган очракта), җаваплар җибәрелергә тиешле почта адресы, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә, шәхси имза һәм дата булырга тиеш.»;

**7 бүлекнең 7.3 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысын - булган очракта) һичшиксез күрсәтә, шулай ук электрон почта адресын күрсәтә йә Бердәм порталда яисә җирле үзидарә органының җавапны яңадан адреслау турында хәбәрнамә җибәрергә тиешле гражданны идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне тәэмин итә торган шәхси кабинетының адресын (уникаль идентификаторын) файдалана. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә теркәргә хокуклы.»;

**18 бүлекнең 6 абзацында** «күрсәтелгән электрон почта адресы буенча» сүзләрен «электрон почта адресы буенча яисә күрсәтелгән Бердәм порталда шәхси кабинет адресы буенча» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Башлык М.Р. Гафаров